**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2025 **Чирмешән авылы**

**№ 278**

**Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы күләмен, 2025 елга торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карарны раслау хакында» 2025 елның 20 февралендәге 42 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 маддәсенең 4 өлеше, шулай ук Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге № 213/пр боерыгы нигезендә расланган «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне, торак урынны карап тоту, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча караны раслау турында», «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы белән **КАРАР БИРӘМ:**

1. Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы күләмен, 2025 елга торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карарны раслау хакында» 2025 елның 20 февралендәге 42 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик (максималь) индексын, 2025 елга торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен 44 процент күләмендә билгеләү турында карарны расларга.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы

Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов